2020 ел Россия Президенты Указы белән Хәтер һәм Дан елы дип игълан ителде. Мордовиянен торле почмакларында сәяси совет әгъзалары һәм депутатлар «Боек Жинvнен 75 еллыгын каршылап» акциясенә кушылдылар. Анын максаты - Боек Ватан сугышы ветераннарын һәм тыл хезмәтчәннәрен Яна ел һәм Жинvнен 75 еллыгы белән котлау. Ул 2019нчы елнын 23 декабрендә башланып 2020нче елнын 19 январендә тәмамланды.   «Бердәм РОССИЯ» партиясе актив әгъзалары, жирле башлангыч бvлекләре секретарьлары Яна ел алдыннан торле районнарыбыз территорияләрендә яшәvче Боек Ватан сугышы ветераннарын һәм анда катнашучыларны тәбрикләvләрен тогәл-ләvчеләр арасында Саранск шәһәр округы депутатлар Советы депутатлары, «Бердәм РОССИЯ» партиясенен жирле сәяси советы әгъзалары Ольга Марисова һәм Людмила Вдовина Кыш Бабай һәм Кар Кызы белән Боек Ватан сугышы ветераннарын якынлашып килvче Яна ел белән тәбрик иттеләр. 627нче номерлы беренчел бvлек членнары, башка ветераннар белән беррәттән, Рәуф Хәсән улы Богдановны да котладылар. Ветераннарга яна ел бvләкләре тапшырылды. «Без халкыбызнын Боек Ватан сугышы елларында башкарган батырлыкларын онытмаска, бу истәлекне бик кадерләп сакларга һәм аны vсеп килvче буынга тапшырырга тиеш. 2020 ел - Боек Ватан сугышында Жинvнен 75 еллыгы алдыннан Ватаныбызга тыныч кvк йозе бvләк иткән кешеләрне истә тоту аеруча моһим»,- дип очрашуда билгеләп vтте Ольга Марисова. Ләмберә районында 6 ветеран һәм Боек Ватан сугышы инвалиды яши. Алар арасында Черемиш авылыннан Шагидулла Сеннәтулла улы Сюбаев һәм Ләмберәдән Касыйм Садыйк улы Искандяров бар. Ләмберә партиячеләре 1 дәрәжә Ватан сугышы ордены кавалеры Касыйм Садыйк улы Искандяровны Яна ел белән котладылар. Унжиде яшьлек егет Боек Ватан сугышына киткән. Курск сугышында катнашкан, берничә танк шартлаткан. «Батырлык очен медаль» («Медаль за отвагу») белән бvләкләнгән. Якын дусларынын vлемен, кеше хәсрәтен кvрдем, ди ул аралашканда. Ветеран партиялеләргә кvрсәткән игътибарлары очен рәхмәт белдерде. «Боек Ватан сугышы ветераннары белән янәшә vткәрелгән минутлар бик кадерле! Безнен тынычлыгыбыз очен, безнен киләчәгебез очен корәшкән кешеләргә хормәт кvрсәтv бик моһим. Һәм без ветераннарга зур рәхмәт әйтәбез», - дип очрашуда билгеләп vтте Ләмберә авылы буенча 427/3 нче бvлек секретаре Лариса Каюм кызы Альмяшева.
Әйтеп китәргә кирәк, регионыбызда Боек Ватан сугышы ветераннарынын саны коннән-кон кими бара. Мәсәлән, Мордовиянен ин зур районнарынын берсе булган Зубово-Поляны районында барлыгы 11 ветеран яши, ә Кадошкино районында - алар очәv. Аларнын барысын да жирле житәкчеләр, партия вәкилләре Яна ел белән котлап

бүләкләр тапшырдылар.

Торбеево районы да акциядә катнашты. Сургодь авылы җирлеге депутатлар Советы депутаты Фәрит Тахир улы Эртуганов белән бергә Торбеево районы башлыгы урынбасары Н.Н. Киров, «Халыкны социаль яклау» ГКУ директоры А.Н. Пайганов 25 декабрьдә үзенең 95 яшьлеген билгеләп үткән тыл хезмәтчәне Хәнифә Хосәен кызы Рамаева янына бардылар. Балалары һәм оныклары каршында Хәнифә Хосәен кызына Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның котлау хаты, чәчәкләр һәм истәлекле бүләк тапшырдылар.
Шулай ук Кадошкино авыл җирлеге сәяси советы әгъзалары һәм депутатлары да бу акциясегә кушылдылар. Бүгенгә Кадошкино районында оч Боек Ватан сугышы ветераны яши, дидек. Районның Латышовка авылындагы политсовет җитәкчесе Надия Байчурина һәм авыл ветераннар оешмасы рәисе Алия Кильмаева Бөек Ватан сугышы ветераннарының котлауларына кушылдылар. Алар сугыш ветераны Шамиль Хосәен улы Емагулов белән Бөек Ватан сугышында вафат булган ветеранның тол хатыны Фяризә Әббубәкер кызы Кильмаеванч (ул быел 100 яшьлек юбилеен билгеләп үтте) Яңа ел бүләкләре һәм чәчәкләр белән котладылар.

Большая Поляна авылы мәктәбе директоры Светлана Наиль кызы Кильдеева белән авыл администрациясе җитәкчесе Наилә Хафиз кызы Долотказина вафат булган ветеранның тол хатыны Мәфтюха Әмин кызы Резаковада булдылар. Ул бераз авырса да, авылдашларын шатланып каршы алды.
Яңа ел алдыннан Ромоданово районы «Бердәм РОССИЯ» активистлары, депутатлар белән бергә, Бөек Ватан сугышында катнашучы Айса Усман улы Рамазанов белән бергә Лидия Васильевна Созаеваны, Екатерина Семёновна Сергунинаны һәм Пётр Андреевич Головны котладылар.
Беренче январь көнне Алтар авылында яшәүче Сафия Хәмзә кызы Исхакованың 95 яшьлек юбилее белән район хакимияте, сугыш һәм хезмәт ветераннары советы, Алтар

авыл жирлеге вәкилләре котлады. Алар Сафия Хәмзә кызына РФ Президенты В.В.Путиннын Котлау хатын һәм район башлыгы С.В.Ведяшкин исеменнән бvләк тапшырдылар.

Героинябыз Алтар авылында туып-vскән, жидееллык мәктәпне дә шунда тәмамлаган. «Мәктәптән сон колхозга эшкә кердем. Мин хәтта ин авыр хезмәтемнән дә курыкмадым. Әмма, кызганычка каршы, тыныч тормыш озак дәвам итми. 1941 елда Боек Ватан сугышы башланды, ин каты һәм канкойгыч, - дип искә ала Сафия Хәмзә кызы. - Мине һәм тагын берничә авылдашымны сугыш вакытында урман кисәргә жибәрделәр. Урман кисv нигездә яшь кызлар һәм хатын-кызларнын фидакарь хезмәте хисабына башкарылды. Без фронтка киткән квалификацияле урман кисvчеләрне алыштырдык. Мин иптәшләрем белән агач ботакларын кистем, аларны повозкаларга тоядем. Бер елдан сон гына ойгә кайттык», - дип сойләде Сафия Хәмзә кызы.
Сугыштан сон ул туган колхозына эшкә кайта. Тиздән Хафиз Ибраһим улы белән таныша; гаилә коралар. Аларнын дvрт искиткеч балалары туа. Бу вакытта Сафия Хәмзә кызы, жиде елга якын, «Красный Узел» станциясенен тимер юлында эшли, ә аннары янадан колхозга эшкә кайта. Безнен героебызнын фотосы һәрвакыт Хезмәт ударнигы буларак Мактау тактасында булды. Эш дәверендә ул берничә тапкыр бvләкләр дә алды. Хәзер Сафия Хәмзиевнанын 8 оныгы һәм 11 оныкчыгы бар, алар анын янына еш киләләр. Без ана сәламәтлек һәм иминлек телибез.
Яна елда Атюрьево, Ардатово, Атяшево, Дубенки, Инсар, Ичалки, Зубово-Поляны, Торбеево, Темников һәм башка районнарда Боек Ватан сугышы ветераннарын һәм тыл хезмәтчәннәрен котладылар. Шулай итеп, республикабызда яшәгән һәрбер ветеран игътибар vзәгендә булдылар.

Наилә Насырова